СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.


14 МАРТ, 1997ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 28 (8040) | Бәясе билгеләнгәнчә.

## Район терлекчеләре рапорт бирә

# КВАРТАЛ ПЛАННАРЫН - СРОГЫННАН АЛДА

Бу көннәрдә район терлекчеләренең кәефе көр, күңелләре күтәренке: алар дәүләткә сөт, ит сату буенча 1997 елның I квартал планнарын вакытыннан алда арттырып үтәп чыктылар. Сөтчелек тармагында эшләүчеләр сөт тапшыру буенча 37 мең центнер итеп җиткерелгән планны 40560 центнер итеп, ягъни 110 процентка [illegible]әделәр. Район планын уңышлы гамәлгә ашыруга квартал заданиесен 180 - 110 процентка үтәгән «Кондырча», «Татарстан», «Родина», Мичурин исемендәге, Муса Җәлил исемендәге, Хафизов исемендәге, «Восход» крестьян хуҗалыклары ассоциацияләре зур өлеш керттеләр. Шәхси сектордан сөт җыюны әйбәт оештырган Сәләнгеш, Кычытканлы, Чулпан, Колбай Мораса авыл җирле үзидарәСоветларының да җиңүгә керткән өлешләре саллы.



Ит сату буенча 8800 центнер күләмендәге квартал планын район терлекчеләре 9704 центнер итеп, ягъни шулай ук 110 процентка башкардылар. «Восход», «Родина», «Чирмешән», Кузнецов исемендәге, «Чишмә» ассоциацияләре, җиткерелгән планны 116 - 182 процентка үтәп, уртак җиңүне тизләттеләр.

Хәзер планнан тыш продукция сату дәвам итә. Яңа елны шундый сөенечле күрсәткечләр белән башлаган терлекчеләребезгә киләчәктә дә зур хезмәт җиңүләре телибез!

30 мартта - сайлау

# ВЕТЕРАННАР АҢА ЫШАНАЛАР

Татарстан Дәүләт Советына сайлау буенча 50 нче Октябрь административ - территориаль сайлау округындагы сайлаучылар арасында 16500 ветеран бар. Алар барлык сайлаучыларның 40 проценты. Димәк, сайлау көнне тавыш бирүнең нәтиҗәләре аларның активлыгына да шактый бәйле булачак.

Районыбыз ветераннары бу округтан Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат итеп билгеле һәм абруйлы, халык арасында ышаныч яулаган һәм аз тәэмин ителгән катлауларның мәнфәгатьләрен реаль эш белән якларга сәләтле кеше күрсәтелүен канәгатьлек белән кабул иттеләр. Район хакимияте башлыгы булып торган чагыштырмача аз гына вакытта да Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин төп социаль проблеманы - пенсионерларга пенсияне вакытында бирү мәсьәләсен хәл кыла алды. Эш хакы түләүдә дә уңай якка үзгәрешләр бар. Аның актив булышлыгы белән райондагы берничә авылга табигый газ кертелде. Шәһәрдә газлаштыру эшен яхшыртуга да зур тырышлык куела, шул максаттан махсус оешмалар төзелә. Илья чиркәвен төзүне төгәлләүгә дә булышлык күрсәтелә.

Бер үк вакытта районда терлекчелектә эшләр күзгә күренеп яхшыра: малларның продуктлылыгы күтәрелә. Игенчелектә алга таба ныклы адым ясау өчен бүгеннән күпләп минераль ашлама тупллана.

Без, ветераннар, Республика Дәүләт Советына сайлангач Ф.С.Сибагатуллин халык, аерым алганда өлкәннәр, пенсионерлар турында тагын да күбрәк кайгыртыр дип ышанабыз. Һәм ветераннарның район Советы барлык ветераннарны, пенсионерларны 30 мартта Татарстан Дәүләт Советына лаеклы кандидат Фатих Сәүбән улы Сибагатуллинны яклап тавыш бирергә чакыра.

**И.ГЫЙЛӘҖЕВ,**
**сугыш һәм хезмәт ветераннарының район Советы рәисе.**

## ШӘҺӘРЛЕЛӘР ИГЪТИБАРЫНА!

**14 март көнне 16 сәгатьтә район культура йортында шәһәрлеләр өчен «Ачык хат көне» үткәрелә. Анда район, шәһәр җитәкчелеге, оешма - предприятие, төрле службалар җитәкчеләре катнашып, шәһәр халкын борчыган сорауларга җавап бирәчәкләр. Шунда ук шәһәрлеләргә 50 нче административ - территориаль сайлау округы буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат, район хакимияте башлыгы Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин белән очрашу, аның сайлау алды платформасының төп моментлары белән танышу да мөмкин булачак.**

**Кичә торак - коммуналь, көнкүреш хезмәткәрләре көненә багышланган тантана белән дәвам итәчәк.**

**Соңыннан Татарстан һәм Башкортостан республикаларының атказанган артисты Фән Вәлиәхмәтов концерты булачак.**

**Кичәгә рәхим итегез!**

Аңлатып үтәбез

## *БАЗАР ТӘРТИП ЯРАТА*

Норлатта азык - төлек һәм промышленность товарлары белән сату итү базарларын аеруның сәбәпләре белән кызыксынып төрле инстанцияләргә мөрәҗәгать итүчеләр әле дә бар. Шуларга җавап йөзеннән район хакимияте башлыгының махсус карарына аңлатма биреп үтәбез.

Карарда билгеләп үтелгәнчә, соңгы елларда шәһәрдә һәм районда азык - төлек һәм халык кулланулы товарлары базары күзгә күренеп киңәйде. Әмма товарларның, бигрәк тә азык - төлекнең хәвефсезлек сертификатыннан башка сату, андый документларның ксерокопияләре белән эш итү, сыйфаты шикле булган товарлар белән сату итү очраклары бар. 1996 елда шундый төр кагыйдә бозган 39 кешегә штраф салынган. Аннан, товарларны билгеләнмәгән урыннарда сату практикасы аеруча борчый. Тәртип тә еш кына нәкъ менә шул урыннарда бозыла. Өстәвенә, андый урынлы - урынсыз сәүдә шәһәрнең санитар торышы начараюга да этәрә.

Һәм менә «Кулланучылар хокукларын яклау турында» РФ Законының үтәлешен тәэмин итү, азык - төлек һәм халык кулланулы товарлары белән базарларда сату итүне тәртипкә салу, шәһәр территориясендә тиешле санитар тәртип булдыру максатында район хакимияте башлыгының махсус карары чыгарылып, анда Норлат шәһәр үзидарә Советына шәһәрдә билгеләнмәгән урыннарда сәүдә итүне тыярга, азык - төлек белән сәүдә итү урыны итеп 60 лет Октября урамындагы колхоз базарын, промышленность товарлары белән сату итү өчен иске сәүдә базасы территориясен (Лесосклад ур.,1) билгеләргә кушылды. Карарда бу эшкә һәм аңа контрольлек итүгә мөнәсәбәте булган оешмалар һәм ведомстволар җитәкчеләренә дә конкрет күрсәтмәләр бирелә.

## Безнең дә якташлык җәмгыятебез бар!

# Исеме - «Нурлыяк» булды

Казан шәһәрендә Октябрь районыннан чыккан кешеләрнең «Нурлыяк» якташлык иҗтимагый җәмгыяте оештырылды һәм рәсми теркәү үтте. Аның идарәсе составына 15 күренекле якташыбыз кертелде. Идарәнең рәисе - якташыбыз Илдар Җәүдәт улы Камалов - «Джой - Лад - Дистрибьюторс» корпорациясе вәкиллегенең генераль директоры; аның урынбасары - шулай ук якташыбыз Галиуллин Тәлгать Нәбиулла улы - филология фәннәре докторы, профессор, Казан Дәүләт университетының татар филологиясе, тарих, көнчыгыш телләр факультеты деканы, академик.

Оешма нинди максатны күздә тота соң? Ул «Нурлыяк»ның 1997 - 2000 елларда эшчәнлек программасында ачык бәян ителә. Генетик, тарихи, социаль тамырлары белән Октябрь районына бәйле кешеләр арасында тыгыз элемтә урнаштырырга омтылып, якташлык оешмасы иң төп бурычы итеп Октябрь районында яшәүчеләр һәм аннан чыгучыларның социаль - иктисадый һәм хокукый сфераларда мәнфәгатен яклауны саный. Анда шулай ук якташларда туган якка, телгә, милли мәдәниятка, әдәбиятка, сәнгатькә, тарихка мәхәббәт уяту, бу җәһәттән районда мәгариф системасын камилләштерүдә булышу, район мәктәпләрендә сәләтле балаларны сайлап, аларның ары таба үсешенә ярдәм итү; Кычытканлы авылында ачылган «Зәмзәмия» мәдрәсәсендә шәкертләргә белем бирү системасын үстерү һәм камилләштерү; Октябрь районы һәм Норлат шәһәре тарихын язу һәм бастыру максатында журналистлардан һәм язучылардан аерым төркем туплау; район тормышында мәдәни, рухи, социаль - икътисадый өлкәләрендә




нәтиҗәлелекле күтәрүгә юнәлтелгән чаралар оештыру; районда һәм шәһәрдә социаль - икътисадый үсеш программасы үтәлешенә ярдәм күрсәтү; галимнәр, җитәкчеләр, белгечләрнең халыкка гуманитар, медицина һәм консультация ярдәме күрсәтү максатында даими рәвештә районга килүләрен оештыру кебек чаралар каралган. Алар быелга эш планында конкрет чагылыш тапканнар.

Хәзер якташлык оешмасы тәүге адымнарын ясый. Районнан чыккан күренекле якташларыбызны теркәү өчен түбәндәге телефон буенча мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Казанда - 32 - 01 - 23.
Норлатта - 2 - 15 - 63.

Түбәндә оешмага кабул итүне сорап гариза язу үрнәген тәкъдим итәбез. Аны сез район газетасы редакциясенең реклама бүлегенә (К.Маркс ур., 19) юллый аласыз.

Председателю правления
Землячества «Нурлыяк»
Камалову И.З.
от____________________
ФИО полностью
проживающего по адресу:
______________________
______________________
______________________
тел.__________________

Заявление.

Прошу принять меня в члены Землячества «Нурлыяк». Обязуюсь соблюдать Устав Землячества, Выполнять решения органов управления и контроля Землячества, вносить вступительные и членские взносы, не допускать действий, которые могут нанести ущерб законным интересам Землячества и достижению уставных целей.

Подпись____________________

# Ә АГАЧЛАР ҺӘР ЯЗ ЯФРАК ЯРА...

*Озакка килмәдек без фани җиргә,-*
*Килеп тап булдык үкенеч - зарга, чиргә...*
*Чишә алмыйча бәла - каза төенен*
*Алып киттек бөтен хәсрәтне гүргә.*

**Омар Хайям.**

Менә ул кабер! Буялган чардуган. Анын эчендә мәрмәрдән шомартып ясалган кабер ташы. Яз айларында ул каберне тирә - яктагы агачларның яшь яфраклары шавы астында да, җәен зиратның хуш исле үләннәре, чәчәкләре әйләнәсендә дә күрдем, ә көзләрен кабер өстендәге чәчәкләр, салкын җил - яңгырдан ышыкланыр урын эзләп, шул мәрмәр ташка сыеналардыр кебек тоела иде миңа.

Унике ел эчендә кабернең өске өлеше бераз басылса да, җәй буе чәчәктә утыручы гөлләре башкалардан аера аны. Ә менә соңгы бер елда анын өстендә шаулап утыручы агач үсеп, матураеп китте, алай гына да түгел, янәшәдәге кабергә таба тартыла сыман. Ата белән улның җаннары тартылган кебек. Юкса, фани дөньяда гел янәшә яшәрләр кебек булганнар иде алар. Җаиз ага Иске Әмзәдә беренчеләрдән булып өй җиткезгәндә, йортына кадәр асфальтлап, бөтен хуҗалыгын гурнича кебек итеп ясаганда да, төпчеген, карт көнендә терәге, асраучысы булыр дип зур өметләр баглаган улы Рәисе өчен дип тырышты бит. Аксыл чәчле, ачык соры төстәге күзле, басынкы холыклы улы да шулай өйләнеп, әти - әнисе белән әби - бабалары нигезендә гомер кичерергә уйлаган иде. Ерак Әфганстаннан хатлар юллаганда да ата - анасын тынычландыра иде: кайтам, авылда калам, өйләнәм...

Рәиснең һәлак булуы турындагы хәбәр Әмзәне генә түгел, тирә - яктагы барлык авылларны да тетрәндерде: солдат бурычын үтәргә киткән, әле яшәү ямен дә татырга өлгермәгән егерме яше дә тулмаган егетнең вафаты һичкемнең башына сыймады. Ата белән ана өстенә төшкән кайгы исә һичнинди бизмәннәр белән үлчәрлек түгел иде: көтмәстән башларына төшкән кайгыдан яшьләре катып калды, йөзләреннән нур качты, вакыт исә туктап калгандай булды. Гаилә тормышытөссезләнде, йөзләрдән ямьнәрен качырды, чәчләргә чал иңдерде бу вакыйга. Ата - ана да танымаслык булдылар. Орчыктай житез, тәрекөмештәй хәрәкәтчән, уңган Минниса апа, җор телле, көр күңелле Җаиз абыйны да алыштырып куйдылармыни? Өйдә кабер тынлыгы урнашты: һәр әйбер, кадакланган һәр кадак улларын, Рәисне хәтерләтә иде.

- Башкача түзә алмыйм, китик авылдан, - диде тын кичләрнең берсендә Җаиз абый кайгыдан авыр башын тотып. Хатыны аны бер сүздән аңлады.

- Кая?

- Кая булса да... Шулай да балалар янында җиңелрәк булыр.

Ана кеше мөлдерәмә тулы чиләкләрен идәнгә куйды да Рәиснең хәрби киемнән төшкән фоторәсемен, соңгы истәлеген күкрәгенә кысты: улым, улкаем...

## Исемнәрен урамнарга бирделәр

**Сержант ҺАДИЕВ Рәис Җаиз улы.**

**- 1966 елда туган.**

**1984 елның 3 нче маенда Октябрь районы хәрби комиссариаты тарафыннан хезмәткә чакырылган.**

**Әфганстанда хезмәт иткән.**

**1985 елның 14 мартында һәлак булган. Үлгәннән соң «Кызыл йолдыз» ордены белән бүләкләнгән.**

**Туган авылы Иске Әмзәдә күмелгән.**

Иртәдән бирле җыелып, төерләнеп торган күз яшьләре ана җанын баласы, анын өчен мәңге исән булган бала рухы белән тоташтырды: без шулай яшерен генә елашырбыз инде, улым.

Шулай Һадиевлар Түбән Кама шәһәре кешеләре булып киттеләр. Олы яшьтә булуларына карамастан, тормышларын яңа баштан башладылар. Һәрхәлдә, алар тирәсендә вагонда яшәүчеләр арасында бу гаиләдән дә өлкәнрәкләр юк иде. Тора - бара фатирлы да, мөлкәтле дә булдылар. Балалары да һәрчак яннарында иделәр. Уллары Әфганстанда һәлак булучылар гаиләсе буларак, льготалар да бирелде үзләренә, бергәләп санаторийларга да йөрделәр. Әмма 1985 ел кышында өзелгән бәгырь, йөзләрдән качкан нур гына кире кайтмады. Ә йөрәк түрендәге һичнинди башка ачы авырту белән чагыштырып булмаслык хәсрәт үзен бер генә минутка да онытырга ирек бирмәде. Норлатка Әфганстанда үлгән егетләрнең ата - аналары белән очрашуга чакырылып, бер генә дә кайтмыйча калганы булмады Җаиз абыйның. Чал башына кигән түбәтәенә ике кулы белән тотыныр иде дә чын ирләрчә атларча тавышсыз гына үксер иде: их, бала, бала... Шулай бала хәсрәтеннән үзе дә фани дөньядан вакытыннан бик алда китеп барырын уйлады микән?! Уйлагандыр. Соңгы сулышын алганда да телендә шул иде: туган авылым туфрагына, улым янына җирләгез.

... Ниһаять, кабер әзер. Туганнары табутны ләхеткә урнаштыралар. Күп тә үтми, янә көрәкләр хәрәкәткә килә, әле берничә сәгать элек кенә казып чыгарылган кызыл балчык, күз яшьләре белән аралашып, табут өстенә коела.

- Хуш, бәхил бул. Синең соңгы теләгеңне үтәдек. Син туган авылың туфрагына күмелдең. Улың янына, тыныч йокла!

Бар хәсрәтен гүргә алып китте Җаиз ага. Миннисасы да калды, балалары да, оныклары да... Норлатта улы исеме белән урам аталуын, ишетү дә, улы кебек үк Әфганстанда батырларча һәлак булган биш якташыбыз хөрмәтенә куелган һәйкәлне күрү дә насыйп булмады ана.

Гомер уза да уза. Кабер өстендәге агачлар тагын яфрак яра. Күп тә үтмәс, тирә - яктагы агачларда төрле кошлар сайрый башлар. Әфганстан ягыннан кайтучы кыр казлары зират өстеннән - кыйгак - кыйгак, «торрыйк - торрыйк» дип моңлы авазларын яңгыратып узарлар: тыныч йокла, Рәис, тыныч йокла дип үтәләрме алар, әллә моңарлагән аналар, аталар, Әфганстан белән бәйле кайгылары булган барча халык күңелендә яткан ачы яраларны искә төшерерләрме?

**Р.ГИНЯЕВА.**

## *Тирәбездә яхшы кешеләр*

# ФИДАКАРЬЛЕК

Ул әнисенә бердәнбер кыз булып үсте. Әнисе Миннеруй апа кырыс холыклы, уңган кеше иде, Румиягә иркәләнеп, тырай тибеп йөрергә туры килмәде. Җырга - биюгә, оештыру эшләренә сәләтле, аралашучан кызны мәктәпне тәмамлауга пионер вожатые итеп эшкә алдылар. Колбай Мораса мәктәбе гомер буе гөрләп торган тормыш, кызыклы класстан тыш һәм мәктәптән тыш чараларны мулдан үткәреп яшәде. Румиягә кадәр вожатый булып бик үткен, сәләтле Нәкыя апа Кашапова (инде мәрхүмә) эшләде. Шундый ныгыган традицияле коллективта эшләү өчен беренче көннән үк бик тырышырга, өйрәнергә, вакытын - көчен кызганмаска туры килде Румиягә. Иң мөһиме - ул балаларны ярата, алар белән уртак тел таба белә иде. Балалар аңа шулай ук тиз тартылдылар, Румия апалары әзерләгән һәр чарага атлыгып килделәр, теләп катнаштылар. Һәм бу бер ел гына түгел, чирек гасырдан артык шулай дәвам итте. Бу еллар эчендә күп нәрсә үзгәрде: Румия Габдрахмановна читтән торып Казан педагогия училищесын тәмамлады, кияүгә чыгып, биш бала анасы булды. Әмма аның тынгысыз балачак кануннарына һич хилафлык иткәне булмады, чәчләре чал төскә керсә дә җаны - тәне белән һаман яшь, һаман армас - талмас, һаман омтылышлы вожак булып кала бирде. Мөгаен, бөтен районда да аның кадәр эш стажына ия өлкән вожатый юктыр. Аның хезмәте заманында комсомолның өлкә, ВЛКСМның Үзәк Комитетлары Мактау грамоталары белән билгеләп үтелде.

Ул вожатый - инструктор исеменә лаек булды. Менә 5 ел инде ул хезмәтен бераз үзгәртте - башлангыч классларны укыта башлады. Нәниләренә аналарча җылылык, шәфкатьле мөнәсәбәт, аларны игелекле, белемле кешеләр итәргә теләү - аның төп омтылышы. Чөнки замана шундыйга китте: миһербанлык, шәфкать, кешелеклелек кебек сыйфатлар дефицитка әйләнеп баралар. Ә Р.Г.Садыйкова аны кешеләрдән күп күрде, үзе дә изгелеген кызганмады. Аларның 5 балалы зур гаиләсендә һәрчак татулык, тынычлык хөкем сөрә, ишекләре дус - ишләре, туганнарыннан бер дә ябылып тормый, картаеп килгән әнисенә урын һәрчак түрдә. Сабыр холыклы Румия байлык, мал артыннан кумады, җаны һәрчак тыныч, күңеле киң булды. Шуңа да бу көннәрдә аны 50 яшьлек юбиле[illegible] белән котларга б[illegible] хезмәттәшләре, туганнары гына түгел, республиканың төрле почмакларына таралган яшьлек дуслары, классташлары да җыелдылар. Ире Мөхтәс гармунда уйнап, Румия җырлаганда, 5 баланың елмаюлы карашыннан, кунакларның җылы котлауларыннан өй эче балкып торды. «Нинди бәхетле гаилә!» дип таралыштык без хезмәттәшебезне котлау мәҗлесеннән. Көнләшеп түгел, чын күңелдән шатланып әйттек бу сүзләрне, чөнки беләбез: Румия Габдрахмановна Садыйкова сабырлыгы, тырышлыгы, кешелеклелеге белән бик лаек бу бәхеткә.

**Р.БОРҺАНОВА,**
**мәктәп директорының тәрбия эшләре буенча урынбасары.**

## *Дөньяда ниләр бар*

### ДӘҮЛӘТ БАШЛЫГЫ КАНӘГАТЬ ТҮГЕЛ

**Борис Ельцин** Генераль прокурор Юрий Скуратов белән очрашуында анын үз ведомствосы эшчәнлегенә контрольне йомшартуына канәгатьсезлек белдерде. Дәүләт башлыгы, «Прокуратурага Генераль прокурор түгел, ә читтән житәкчелек итәләр», дип белдерде.

### ЧИНОВНИКЛАР АЗАЯ

**Казахстан Президенты** Нурсолтан Назарбаев дәүләт идарәсенең үзәк органнары санын яртылаш кыскарту турындагы указга кул куйды. Хәзерге 47 шундый органнын 24се генә калачак.

Дәүләт башлыгы урыннарда хакимият органнары структурасына реформа ясалачагын әйтте.

### ЯҢА КОСМОДРОМ

**Амур өлкәсендә** Свободный тайга яңа космодромы эшли башлады. Моннан җибәрелгән «Старт - 1» ракетасы орби[illegible] 87 килограммлы «Зея» спутнигын чыгарды. [illegible] оборона министрлыгы мәнфәгатьләрендә файдаланылачак. Моның өчен әле күптән түгел стратегик максаттагы ракета гаскәрләре дивизиясе урнашкан Свободныйны сайлап алдылар. Бүген биредә ракеталар һәм җиңел класслы спутниклар өчен монтаж - сынау корпусы җиһазланды, команда пункты булдырылды, телеметрия мәгълүматларын кабул итү станциясе эшли.

(«В.Т»)

## *Ике Ландыш*



Насыйрова һәм Бикиниева (рәсемдә) - таналар группасында беренче ел гына эшләсәләр дә үзләрен яхшы яктан танытырга өлгерделәр инде. Эштә ныгып үскән яшь хатыннар үз участокларында тулы тәртип булдырдылар, хуҗалыкның сөт терлекчелеген югары продуктлы маллар белән тулыландыруның әһәмиятен аңлап эшлиләр. Сүз уңаеннан, Л.Насыйрованың ире Галимҗан да терлекчелектә, ул да булдыклылыгы белән мактаулы. Ике Ландыш исә малларны яратып, хезмәтләрен җиренә җиткереп башкарулары белән «Кондырча» КХАсы товарлыклы - сөтчелек фермасы коллективына бик тиң, бик хуш килделәр.

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## Хуҗалыкларда еллык хисап

# ТӘКЪДИМНӘР КҮП БУЛДЫ

«Чирмешән» КХАсы хезмәтчәннәренең еллык отчет җыелышы, үткән җыелышлардан аермалы буларак, элек мөстәкыйль булып яшәгән, узган ел азагында гына берләшкән хуҗалыклар эшчәннәренең уртак җыелышы иде. Аны отчет доклады белән ассоциация рәисе Илһам Йосыфхан улы Хәниев башлап җибәрде. Ул узган елгы нәтиҗәләргә киң тукталып, аларны һәръяклап анализлады, тармаклардагы кимчелек - җитешсезлекләрне бетерергә кирәклеген ассызыклады. Агымдагы елда алда торган эш - максатларны бәян итте. Илдәге сәяси, икътисади тотрыксыз чорда базар шартларында югалып калмас өчен яңа алымнардан, технологияләрдән кыю файдаланырга кирәклеге хакында сөйләде. Ә эшлисе эшләр бар хуҗалыкта. Гәйтән һәм Кәкре Атау авылларында ярты юлда тукталып калган газ кертү эшен дәвам итәргә, Кара Күл авылы янында Чирмешән елгасы аша салынырга тиешле күпер дә быелдан калмастыр, шәт. Икенче бригадада терлекләр өчен җәйге лагерь төзү, малларны бәйләүсез асрау технологиясе кертелгән фермаларда биналарны реконструкцияләү, оештырылачак яңа тармак - дуңгызчылык өчен тораклар булдыру - быел башкарыласы эшләр. Бу хуҗалык җитәкчесе докладында да, ассоциациянең баш зоотехнигы чыгышында да киң чагылыш тапты. Р.Сираҗетдинов үзе җитәкләгән тармак эшчәнлегенә киңрәк тукталды. Сөйләрлеге бар иде, узган ел сөт һәм ит җитештерү буенча хуҗалык районда өченче урынга чыкты. Тармак җитәкчесе умарта тотып бал җитештерүнең хуҗалык өчен төшемле эш икәнен (ә ул икенче бригадада гына да 3 тонна), корт ояларын сатып та өстәмә табыш алырга мөмкинлеген әйтеп узды.

Хуҗалыкта төп тармакларның икенчесе булган кырчылык тармагы җитәкчесе - хуҗалыкның баш агрономы В.А.Беляев чыгышыда төпле, һәр сүзе дәлилләнгән иде. Ул быел төп игътибарны сабан, уҗым бодайлары кебек безнең җирдә югары уңыш алу мөмкинлеге булган культураларга, бөртек технологиясе белән кукуруз игүгә бирергә кирәклеген әйтте. Ашлаган җир аш бирә, диләр. «Амбарда, складта ятканы түгел, кырга чыгарылганы, җиргә кертелгәне генә ашлама аның», - диде Валентин Андреевич үзенең чыгышында. Бер килограмм ашлама дүрт килограмм, яхшы килгән елда алты килограммгача иген уңышы җыеп алырга ярдәм итә икән, быел технологияләрне саклап югалтуларга юл куймыйча эшләгәндә (ашламаны хуҗалык быел мулдан туплады) икмәк уңышын 40 центнерга җиткерә алабыз, диде баш агроном. Беренче бригада агрономы М.Галимов үзенең чыгышын язгы кыр эшләренә, үткәреләчәк техник чараларга багышлады. Ә менә баш инженер Х.Насыйбуллинның чыгышы, үз вазифасына игътибар биреп җиткермәве өчен, хуҗалык җитәкчесенең тәнкыйтенә юлыкты. Ассоциациянең баш икътисадчысы И.Идиятуллина узган елгы эш нәтиҗәләрен анализлаганда да, агымдагы елга план белән таныштырганда да сүзен эш күрсәткечләре, саннар белән дәлилләп барды. Районда тарала башлаган яңалык - кооперативлар оештыру, аның файдасы хакында да сөйләде баш белгеч. Узган елны мөстәкыйль хуҗалыклар булып яшәгәч, ике бригаданың да ревизия комиссияләре аерым - аерым отчет тотты. Комиссия рәисләре Х.В.Нурмөхәммәтов та, Г.М.Терентьев та үз чыгышларын җентекләп әзерләгәннәр булып чыкты. Бер генә җитешсезлек - кимчелек тә аларның күз уңыннан читтә калмаган. Аларның тәкъдимнәре дә бар иде, әйтик ни өчен әле Иске Авыл кирпеч заводын яңадан эшләтеп җибәрмәскә? Яки ни өчен элекке еллардагыча яшелчәчелек бригадалары оештырмаска? Ревизия комиссияләренең башка киңәш - тәкъдимнәрен дә хуҗалык җитәкчеләре игътибарга алды. Җыелышта хезмәт коллективы белән хуҗалык җитәкчелеге арасында төзелгән коллектив килешүне ассоциациянең профсоюз комитеты рәисе М.С.Хәлиуллин тәкъдим итте. Җыелышта район хакимияте башлыгының . беренче урынбасары Ю.В.Терентьев, АПК работниклары профсоюзы райкомы белгече Т.Һ.Фәйзуллина, хуҗалыкның шефлары - райпо рәисе, бу төбәктән район Советы депутаты М.С.Моратов катнаштылар. М.С.Моратов та, Ю.В.Терентьев та үз чыгышларында хуҗалыктагы эшләрнең барышын уңай бәяләделәр. Илдәге, республикадагы, райондагы икътисадый хәлне анализлап, алар бүгенге авыр шартларда хуҗалык итүнең яңа технологик алымнарын кулланып эш иткәндә генә уңышка ирешү мөмкин икәнлеген ассызыкладылар. Юрий Владимирович 30 нчы мартта булачак сайлаулар уңаеннан җыелган халыкны Татарстан Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат Ф.С.Сибагатуллин кандидатурасы белән таныштырды, сайлаучыларны 30 мартта тавышларын аңа бирергә чакырды.

Җыелыштагылар узган елда лаеклы ялга чыккан колхозчыларны хөрмәтләделәр. Аларга истәлек бүләкләре тапшырылды. Хуҗалыкның узган елда алдынгылыкны бирмәгән, тырышлыклары белән танылган хезмәтчәннәре дә җыелыштан бүләксез китмәде.

**Җ.ШАКИРОВ,**
**хәбәрче.**

# ҮЗЕҢӘ ДИП ЭШЛӘСӘҢ ГЕНӘ

Синдряков исемендәге КХА гомер - гомергә районда үзенә бер аерым чутта торды. Сүз хуҗалыкта производство мәсьәләләрен ипле алып бару белән беррәттән күпчелек социаль - көнкүреш проблемаларын да хәл итеп калынуы турында гына түгел. Иң мөһиме - биредә хуҗалык итү өлкәсендәге бар булган алдынгы тәҗрибә сыналмый калмады. Авылда хуҗалык исәбе дигән нәрсә тарала башлаган елларда янача эшләргә өйрәтүле семинарлар нәкъ менә аларда уздырыла иде. Колхозның терлекчелегендә дә, игенчелегендә дә хуҗалык исәпле заданиеләр буенча эшләү тәҗрибәсе матбугатта да киң яктыртылды. Аренда ысулы турында сүз чыккач та синдряковлылар аны сынауга кыю алындылар һәм анысы да нәтиҗәсез булмады.

Монысы бер. Икенчедән, бу хуҗалык аеру - кушу шаукымының да иң үзәгенә эләккән хуҗалыкларның берсе булды. Әле менә соңгы тапкыр кушылганнан соң кәгазьләрне дә рәткә китереп бетерергә өлгермәделәр - хуҗалык «Норлат» агрофирмасы составына кертелде. Шуңа күрә синдряковлыларның еллык хисап җыелышында сүз былтыр башкарылган эшләр хакында гына түгел, инде яңа шартларда ничек эшләү турында да барды. Җыелышта агрофирманың һәм ит комбинатының генераль директоры Р.С.Чахмахчев, «Татмясопром» холдинг компаниясенең вице - президенты Т.Н.Хәмидуллин катнашып чыгыш ясадылар.

Ассоциация рәисе С.И.Белогубовның хисап докладында гаять кискен, әмма эшлекле төстә төзелгән иде. Ул бер елда башкарылган эшләрне, күпме продукция җитештерелүен санап чыгуга гына кайтып калмады. Дөрес, алары хакында да әйтелде, әмма доклад башыннан ахырынача узган елгы эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген анализлауга корылган иде. Рәиснең максаты продукцияне мөмкин кадәр арзангарак төшереп җитештерә алган очракта гына, һәр тармакта, һәр эш участогында чыгымнарның күзгә күренеп торганнарын да, эчкәрерәк ятканнарын да ачыклап, аларны киметү турында бергәләп кайгырткан тәкъдирдә генә икътисадый - финанс хәлен яхшырту мөмкин булачагын җыелыштагы һәр кешенең аңына барып җитәрлек итеп төшендерү иде. Докладчы бу уңайдан гаять гыйбрәтле мисаллар китереп үтте. Аерым алганда, кырчылыктагы аренда звенолары белән идарә арасындагы мөнәсәбәтләр турындагы мисал игътибарга лаек иде. Чыннан да, кырчылыкның иң очсыз саналган продукциясе - салам да, аны җыю, эскертләү һәм ташу мәсьәләсендә уйлап эш ителмәгәндә ахыр чиктә, бердән, бик кыйммәткә төшәргә, икенчедән, никадәр мәшәкать китереп чыгарырга мөмкин икән. Шуңа да Сергей Ильич моннан ары арендадагы кырчылардан саламны басуда түгел, ә ферма янына кайтарып урнаштырылгач кына кабул итү мәслихәт булачак дип фикер йөртә. Һәм мондый уйландырырдай мисалларны хуҗалыкның барлык тармакларыннан да китерергә мөмкин. Иң мөһиме - алардан һәркем үзенә тиешле нәтиҗәне ясасын, икенче төрле әйткәндә, экономия, үзкыйммәт кебек төшенчәләр турында җитәкчеләр һәм бухгалтерия аппараты хезмәткәрләренең генә түгел (баш бухгалтер Н.И.Храмованың хуҗалыкның керемнәре һәм чыгымнары турында барлык ассоциация членнарына мөрәҗәгать итеп әйткән сүзләре залдагы берәүне дә битараф калдырмагандыр), гади хезмәткәрләрнең дә башы бераз авыртсын. Дөрес, гомер буе гел бер эшне башкаручы терлекче яки механизатордан моны коры сүз белән генә таләп итеп булмый. Шуңа күрә хуҗалыкта инде кулланылышта булган хуҗалык исәбе ысулын, аның чыгымнарны контрольдә тотуның чек системасын җиренә җиткереп алып бару турында кайгырту зарур. Моның шулай кирәклеге, шунсыз алга таба адәм рәтле яшәүгә өметләнеп булмаячагы турында җыелышта сүз кискен булды. Хуҗалыкны агрофирма составына кертү генә проблемаларны үзеннән үзе генә хәл кылмаячак. Хуҗалык нинди генә структура составында булса да, һәркемнең үз эш участогында намус кушканча хезмәт итүе, хуҗалык кассасындагы акчаны да үз кесәндәге кебек үк санап тотарга күнегүе шарт. Шуңа да агрофирма җитәкчеләренең җыелыштагы чыгышларыннан ачык аңлашылганча, фирма канаты астына керү хуҗалыкка бераз җиңеллек китерсә дә, гел «абзый»га гына салынып яшәргә мөмкин булмаячак. Нинди генә хуҗа килсә дә, иң элек эш турында сүз кузгатачак бит. Эш һәм тәртип турында. Соңгысы теге яки бу производство участогында үз вазифаңны җиренә җиткереп башкару турында гына түгел, чыгымнарны барлау, алны - артны карап эш итү мәсьәләсендә дә ныклы тәртип булдыру дигән сүз. Барыбер иң элек үзенә дип эшләргә кирәк.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

## РЕСПУБЛИКАБЫЗДА

**Язгы чорда юлларны ватылу - җимерелүдән саклау максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 1 апрельдән 10 майга кадәрге чорга гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт хәрәкәтен чикләүне кертә.**

Бу юлларда барлык маркалардагы чылбырлы тракторлар, К - 700 һәм Т - 150 тибындагы көпчәкле тракторлар, гомуми авырлыгы 9 тонна һәм аннан да күбрәк булган автомобильләр, ә федераль дәрәҗәдәге юлларда гомуми авырлыгы 7 тонна һәм аннан да күбрәк булган автомобильләр йөрүе тыела.

***

**Тимер юл транспортында пассажирлар йөртү тарифлары 1 марттан тагын 10 процентка күтәрелде.** Мәскәүгә «Татарстан» фирма поездында бару өчен хәзер купе вагонына 252.000 сум, плацкартка - 135.000 сум, ә махсус вагонга 444.400 сум түләргә кирәк. Гадәти поездларда йөрү дә кыйммәтләнде. Мәсәлән, Казаннан Волгоградка бару бәясе 166.100 сум (купе) һәм 103.800 сум (плацкарт) тора.

(«В.Т.»)

## *Почтальон алып килә...*

# Энҗе бөртегедәй Энҗебез бар...

Энҗе Бикташева күп еллардан бирле Түбән Норлат авылында хат ташучы булып эшли. Авыл халкы аның җил - җил атлап газеталар, хатлар таратуын түземсезләнеп көтеп ала. Бу - Энҗе озак көттергәннән түгел, ул бик җаваплы, җитез хезмәткәр, кайткан корреспонденцияне тиз арада иялӘренә җиткерергә тырыша. Ә көтеп алулары - Энҗе белән бер күрешеп хәл - әхвәл сорашу да һәркемгә ничектер сөенеч, яктылык китерүдәндер, мөгаен. Мөлаем йөзле, кешелекле хат ташучыбызның тормышы да көйле, түгәрәк. Ире Галиулла да тәртипле кеше, гаиләләрендә татулык, тәгәрәшеп балалары үсеп килә. Энҗебезне бөтен авыл белән яратабыз, минем исә аны күргән саен күңелемдә шигырь юллары туа.

Энҗе бөртегедәй
Энҗебез бар,
Авылда ул үзе - бер
генә.
Хатлар белән шатлык
өләшә ул,
Бар эшкә дә ничек
өлгерә?!
Энҗе бөртегедәй
Энҗебез бар,
Үзе тыйнак, үзе
ягымлы.
Аны көтә һәркем,
көтә һәр көн,
Рәхмәте зур бөтен
авылның.
Энҗе бөртегедәй
Энҗебез бар,
Исеменә килгән -
җисеме.
Йөрәгеңә дәва - шатлык сүзе,
Йөзе нурлы, үзе
сөйкемле.

**Т.АЛЯКИМОВА.**
**Түбән Норлат авылы.**

## ХАТ ӨЛӘШӘ ГӨЛЧӘЧӘК

Ике Әмзә, Чурабатыр торак пунктларына хезмәт күрсәтә торган элемтә бүлеге Яңа Әмзә авылында урнашкан. Иске Әмзә һәм Яңа Әмзә арасы өч километрлап җыела. Ике авыл эчен дә санасаң, Иске Әмзә авылы почта таратучысы Гөлчәчәк Похачеваның көн саен күпме юл үтүен санап чыгару кыен булмас. Әмма моңа да карамастан, Гөлчәчәкнең һичкайчан зарланганын ишетмәссең: җилкәсенә калын сумка элеп көн саен элемтә бүлегенә килә ул. Газета - журналлар, хатларны адресатларына үзвакытында илтеп җиткерү өчен аларны шул ук көнне тарату чарасын да күрә. Һәм һәркөн шулай. Быел шушы эшенә керешүенә дә 9 ел булды инде. Ходай аны исәнлектән аермасын, көн саен шулай авылдашларын сөенечле хәбәрләр белән шатландырып торсын иде.

**С.ФӘТХЕТДИНОВА,**
**хәбәрче.**
**Яңа Әмзә авылы.**

Очрашу

# ИСКЕ... ЯҢА ТАНЫШЫБЫЗ

***Р**едакциягә беренче тапкыр керүе иде аның.*

*- Миңа 65 яшь, хатыным Роза белән тормыш коруыбызга 40 ел була, шул уңайдан балаларга котлау бастырасы иде газетада,- диде ул шаяргандай итеп.*

*- Киресенчә, балаларыгыз үзләре сезне котлар инде,- дип әйтеп, абзыебызны озатырга җыендык без.*

*- Алар котлый да, котлый инде. Үземнең котлыйсы килгән иде. Алар булмаса, мин сау - сәламәт килеш шул яшемә җитәр идем мени?! Шулар дип яшибез әниләре белән...*

Карсак гәүдәле, җор телле бу абзыйдан җиңелчә генә котыла алмаячагыбызны аңлап, аны азаккача тыңлап бетерергә булдык. Аннары аның белән сөйләшү дә ничектер җиңел, шул ук вакытта кызыклы да иде. Яңа танышыбыз - Фома авылы кешесе Хәлим Гафуров булып чыкты. Фамилиясеннән үк аңлашылганча, Фомада Гафуровлар гаярь нәсел санала. Эшчәннәр диләр алар турында һәм өстиләр: мәзәкчәннәр. Хәлим агага да бу ике сыйфатның һәркайсын мул итеп биргән ходай. Гомер буе «Игенче» ассоциациясендә механизатор булып эшли ул. Шофер исә яраткан шөгыле. Әңгәмәдәшебез белән сөйләшә - сөйләшә элегрәк танышлыгыбыз булуын да ачыкладык: пычрак, карлы яңгыр явып торган көннәрнең берсендә юлсыз Фомадан аның танк кебек теләсә нинди пычракны ерып йөрүче ЗИЛ - 157 автомашинасына утырып кайтуыбыз хәтергә төште. Өч кешелек кабинасына без биш хатын - кызны утыртып, олы юлга чыгарган иде ул. Ни чана, ни арба вакытта басу өстеннән салынган тирән колеялы юлдан курка - курка баруыбыз да истә калган. Ә Хәлим абый, әйтерсең лә эреп баручы туфрак катыш боз өстеннән түгел, ә асфальттан бара. Рульне дә ышанычлы тота, хәрәкәтләре дә җитез. Шул ук вакытта, без, кыз - кыркынга кызыклы мәзәк тә сөйләп ала. Сезне генә түгел, сездән дә мөһимрәк йөк күчергән булды анысы. Безнең юллар бит тиз генә үтмәле түгел иде. Үз гомеремдә бәби табарга илткәндә унбер хатын - кыз шифаханәгә барып җитә алмыйча, шушы кабинамда бәбиләделәр. Кайсыларына кендек бабасы булырга туры килде хәтта.

- Хәзер юллар да яхшы, әмма «поезд» китте шул инде,- ди ул елмаеп. Поезд дигәне, минут - сәгать санап алга «чабучы» гомерне әйтүедер инде. - Әмма гомер заяга узмады, йорт тутырып балалар үстердек...

Шуннан Хәлим абый белән балаларын санап киттек: Гүзәлиясе Норлатта яши, Кадрия Чаллыда, Гөлнур Печорада, Фәрит Башкириядә, Хәлиле авылда икән. Ришаты исә үз янында. Соңгылары турында Хәлим абый аеруча җылы сөйләде. Спасс районыннан килен булып төшкән Айсылуны кызы урынына күрүен, ике оныгының берсеннән - берсе матур булуын, бергә - бергә татулыкта, муллыкта яшәүләрен сөйләде.

- Әлегәчә берсе дә кешедән аерым кайгы китермәделәр, шуңа шатланам, югыйсә, аерым тәрбияләү өчен вакытыбыз да булмады,- дип дәвам итте ул сүзен.

Анысы шулай инде. Кырык ел берөзлексез машина руле артында булганда нинди генә рейслар башкарырга туры килми аңа. Гаилә бераз мантысын дип көн - төн эшли, хатыны Роза да чабу тутырып бала тудырдым дип, ире тапканны көтеп утырмый: Хәлим абый әйтмешли, эштән кайткан арада бәбили дә, өлкәнрәкләренә карарга кушып, янә эшенә ашыга. Көн дәвамында берничә тапкыр имезергә дә кайтып өлгерә әле. Шуңа 50 яшеннән пенсиягә чыкса да, кискен генә эштән туктый алмыйча, тагын берничә ел сыерлар сава. Шөкер, әле дә сау - сәламәтлегенә зарланмый: җил - җил эшләп йөри, балаларына булыша, оныкларын үстерешә, ә алар аз түгел: җәмгысе бер дистәгә җыела.

- Тату яшибез, пенсияне үзвакытында мул итеп алабыз, терлек - туар асрыйбыз, гомумән, тормыштан канәгать мин,- ди Хәлим ага.

Хәзерге акча кытлыгы заманында мондый сүзләрне сирәк кешедән ишетәсең, бүгенге тормыштан канәгатьләнү алып шөкерана кылып яшәүче оптимистик рухлылар да күп түгел арабызда. Аның белән сөйләшкәч, безнең дә күңелләребез күтәрелеп китте, яшисе килә башлады

Соңрак булса да, бездән дә туган көнең белән котлау кабул ит, Хәлим ага. Ары таба да шундый көр күңелле, тормыш сөючән бул, сәламәтлегең белән картай, һәм... безнең янга да кергәләп йөр.

**Р.ГИНЯЕВА.**

# Газета - укучы - газета

## БАРЫБЫЗ ДА ҮЗ ИТТЕК

Вахит Сафиуллович Вәлитов тәҗрибәле педагог булса да, безнең мәктәп - гимназиядә беренче елын гына эшли әле. Әмма ул укытучылар һәм укучылар арасында тиз арада үз кешегә әверелде. Ул ачык йөзле, үз эшенә җаны - тәне белән бирелгән укытучы. Аның дәресләренә балалар теләп йөриләр, Вахит Сафиуллович үткәргән бер генә чарадан да читтә калмыйлар. Хәер, мавыктыргыч итеп оештырылган спорт уеннарыннан кайсы баланың читтә каласы килсен икән?! Әле менә «Ягез әле, егетләр» дип аталган атналык уеннарда катнашуга мәктәпнең икенче сыйныфыннан алып унберенче сыйныф укучылары тартылды. Алар үзләрен җыр һәм строй смотрында, турникта тартылуда сынадылар. Противогазлар кию, аркан тарту һәм ярышның башка төрләрендә дә һәркем актив булды.

Өлкән сыйныфлар укучылары арасында гер күтәрү дә мавыктыргыч булды. Анда беренче урынны унберенче сыйныф укучысы Рәдиф Митаков яулады. 24 килограммлы герне 18 мәртәбә күтәрде ул. Ә герне 10 тапкыр югары чөйгән Илшат Гыйләҗетдинов (9 нчы сыйныф) икенче булды. Унберенчедә укучы Айрат Гатауллин исә турникта тартылу буенча яхшы нәтиҗә күрсәтте.

Гомумән, мәктәбебез егетләре атна буена көч сынаштылар, ә кызлар исә үз сыйныф егетләре өчен ничек дулкынландылар бу көннәрдә. Менә, ичмасам, дуслык кая сынала икән ул!

Күңелләрдә матур, онытылмаслык тәэсирләр калдырган атналык артта калды. Ә Вахит Сафиуллович аларның яңаларын, тагын да кызыклыракларын оештыру уе белән яна бүген. Без, аның янәшәсендә эшләүче педагоглар, хезмәттәшебезнең тырышлыгын якыннан күреп торып аңа сокланабыз. Киләчәктә дә энергияле, балаларга мәхәббәтле, үз эшенең остасы булып калсын иде ул.

**Р.МӘСЛӘХОВА.**
**Киекле авылы.**

## Бездә радио сөйләми

Элегрәк йортыбызда радионокталар эшли иде. Радионы ачып куя идек тә, ул көне буе сөйләп тора иде. Йортыбызда радио эшләми башлаганга елдан артык инде. Ни сәбәпле туктады икән ул? Юкса, радио өчен дә һәрвакыт үзвакытында түләп бара идек.

Күрше йортларда яшәүчеләрдән ишетеп торабыз: аларда радио эшли. Хәзер Норлаттан трансляцияләнә торган җирле радиотапшыруларны да тыңлыйлар алар. Ә без боларның һәркайсыннан мәхрүм. Бәлки бездә радио линияләренә ремонт таләп ителәдер. Шулай булса, без элемтә узелына ремонт өчен дә түләр идек әле. Минем теләгемә йортыбызда яшәүчеләрнең барысы да кушыла.

**Циалковский урамындагы 7 нче йортта яшәүчеләр исеменнән З.Әһлиуллина.**

## БЕЛДЕРҮЛӘР

### Сатабыз

**Нефтьчеләр урамында бер бүлмәле фатир.** Тел.: 5 - 25 - 36 (кичке 6дан соң).

***

**5 х 4 метрлы төрткесез бура.** Тел.: 4 - 13 - 33.

***

**Дача участогы.** Дружба ур., 33.

***

**30 ат көчле, әйбәт хәлдәге салонлы, 20 мең километр йөргән, ЗАЗ - 966ны - запас частьларга.** Тел.: 2 - 26 - 27.

***

**«Нива» автомашинасы (кыйммәт түгел), материаллары белән 2,5 х 3 метрлы мунча.** Адрес: Елаур авылы, тел.: 4 - 32 - 28.

***

**Пушкин поселогында йорт нигезе салынган участок.** Адрес: Нефтьчеләр ур., 4 - 19.

***

**1993 елгы ВАЗ - 2106.** Тел.: 5 - 21 - 30.

### Сатабыз яки алмаштырабыз

**СПТУ микрорайонында төзеп бетерелмәгән аерым йортны сатабыз яки өстәмә түләп ике бүлмәле фатирга алмаштырабыз.**

Адрес: 60 лет Октября ур., 11 - 15 (кичке 5 тән соң).

### Алмаштырабыз

**Әфган поселогындагы төзелеп бетмәгән йортны (материаллары белән) - 2 бүлмәле фатирга.** Адрес: Дружба ур., 33.

***

**Ике бүлмәле фатирны ике берәр бүлмәлегә.** Адрес: Совет ур., 79 - 16.

***

**Ашлыкка яки иткә - яңа ЮМЗ - 6А тракторы, 380 вольтлы эретеп ябыштыру аппараты, барлык төр автомобильләргә һәм тракторларга резина, тракторларга һәм автомобильләргә запас частьлар.**

**Бәяләр - килешү буенча.**

Адрес: Самара өлкәсе, Кошки районы, автовокзал тирәсендәге «Автозапчасти» кибете, тел.: 2 - 14 - 99.

### Күрүче юкмы?

**Көнчыгыш - Европа нәселле аклы - каралы, 8 - 9 айлык, Лада кушаматлы овчарка югалды. Сак булыгыз: эткә котыруга каршы укол ясалмаган.** Табучылар булса, Ленинград ур., 14 адресы буенча хәбәр итүләрен сорыйбыз.

«Татнефть» АҖнең Норлат разведка идарәсе коллективы, **Разыйх Насыйбулла** улы **Мостафинның** вакытсыз вафат булуы турында белдереп, мәрхүмнең гаиләсенең һәм якыннарының авыр хәсрәтен уртаклаша.

Зирекле урта мәктәбе коллективы мәктәп хезмәткәре Саимә Кәрим кызы Галиеваның әтисе **Кәрим Галиевның** вафат булуы сәбәпле тирән кайгысын уртаклаша.


## Белдерүләр

**Агропромбанкның Норлат-Октябрь бүлекчәсе юридик һәм физик затларга депозит операцияләре буенча хезмәтләр күрсәтә. Кыйммәтле әйберләрне саклау шартларын банк бүлекчәсендә белешергә мөмкин.**

Адрес: Совет ур., 113, тел.: 2 - 22 - 20, 2 - 22 - 71.

### Эшкә чакырабыз

**Район эчке эшләр бүлегенең ведомстводан тыш сак бүлегенә ОПС электромонтеры эшенә радиотехниклар кирәк.**

Администрация.





## ҮЛЕП ТЕРЕЛҮ

Тарихта үлгәннәрнең терелү очраклары аз түгел. Шагыйрь Петрарка белән булган хәл бөтен дөньяга мәгълүм. Ул, үзен күмәргә берничә генә сәгать калгач, терелә һәм шуннан соң 30 ел яши. Соңгы вакытта, ягъни 1964 елда Нью - Йорк моргында булган хәл дә гаҗәпләндерерлек: «мәет», кинәт уянып, аны яручы патологоанатомның бугазына ябыша. Анатом шунда ук шок хәлендә җан тәслим кыла. Бу гасыр башында инглиз табиблары тикшеренүләр нәтиҗәсендә ел саен 2,5 мең кеше тере көе күмелә, дигән фикергә килгән. Шуннан соң 60 нчы еллар азагында Лондонда йөрәкнең бик акрын электрик активлыгын да сизә торган аппарат уйлап табалар. Аны моргта беренче сынау вакытында ук бер кызның тере булуы ачыклана.

## КӨМЕШКӘ КӨМЕШ ТҮГЕЛ ШУЛ

Һиндстанның Ориссо штаты хөкүмәте көмешкә кайнатучыларга каршы көрәшнең нәтиҗәле ысулын уйлап тапкан. Спирт җитештерүчеләр иң түбән каста һәм ыру ирләрен эчерәләр икән. Хакимият моны тыюны таләп итеп, полициягә түгел, күптән инде үз гаиләсендә исерек ирдән җәфа чиккән хатын - кызларга мөрәҗәгать иткән. Хәзер бу ханымнар, үзләренә закон тарафыннан бернинди эзәрлекләү булмасын белеп, очраган теләсә кайсы «аракы һәм ликер предприятиесе»н җимерә, юк итә икән.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2083 данә. Заказ № 6012